ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында.**

Югары Ослан районында яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә катнашуга хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында” 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, Югары Ослан муниципаль районы Советының 04.06.2020 ел, № 58-670 карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү турында нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген (алга таба - җәмәгать фикер алышуларын оештыручы) билгеләргә.

3. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручы - коллегиаль киңәшмә орган составын расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Әхмәтшин;
- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. Д. Сәгъдиева;
- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру-хокукый һәм кадрлар эше башлыгы Н.В. Пичугина;
- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов.

4. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә иҗтимагый фикер алышулар уздыруны тәэмин итәргә.

5. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү 2025 елның 9 октябреннән дә соңга калмыйча тәгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы нигезендә иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәр әзерләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин